| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-77/кс

«ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 17 ноябрендәге 10-40/кс номерлы карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020 елга эчә торган суга, су агызуга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ЭКО» ресурслар белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.11.2017 №10-40/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 21.11.2018 №10-54/кс карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2017 № 10-40/кс карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-77/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм су агызуга 2018-2020 еллар өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 24,27 | 24,27 | 24,25 | 24,25 | 24,25 | 25,15 | 26,09 | 26,13 | 25,94 | 25,94 | 25,94 | 25,98 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.11.2017 № 10-40/кс карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-77/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы
«ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен
2018-2020 елларга эчә торган суга һәм су агызуга тарифларны
җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнары-ның база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «ЭКО» ресурс белән тәэмин итү оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2018 | 1700,46 | 1 | - | - | 0,88 |
| | | 2019 | 1799,73 | 1 | - | - | 0,88 |
| | | 2020 | 1835,18 | 1 | - | - | 0,88 |
| 1.2 | Су агызу | 2018 | 2747,85 | 1 | - | - | 0,38 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2870,36 | 1 | - | - | 0,38 |
| | | 2020 | 2926,90 | 1 | - | - | 0,38 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге